**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ АККҮЗ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**423744, Аккүз авылы,**
**Үзәк ур.,1 нче йорт.**
**Тел/факс 3-44-42**

**СОВЕТ АККУЗОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423744, село Аккузово,**
**ул.Центральная,дом 1.**
**Тел/факс 3-44-42**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«18» ноября 2024 года** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге составына керүче Михайловка авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, гражданнар Җыенының 2024 елның 11 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә Аккүз авыл җирлеге Советы карар итә:

Аккүз авыл җирлегенең Михайловка авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешегә, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан , 80 яшькә җиткән, мобилизацияләнгән гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар(катнашкан) булып торучы гражданнарнын һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, аларның саны авыл халкының гомуми санынннан 30 проценттан артмаска тиеш. 2025 елда Аккүз авылындагы Михайловка авыл җирлеге территориясендә 1570(Бер мең биш йөз җитмеш) сум күләмендә бер тапкыр җыела торган түләү кертергә, һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :

1.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: (грейдерлау, кардан чистарту, юл кырыйларын чаптыру).

2.Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә **21** граждан кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан саны **11** .

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлегенең Михайловка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип , гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Аккүз авыл җирлегенең Михайловка авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешегә, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан , 80 яшькә җиткән, мобилизацияләнгән гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар(катнашкан) булып торучы гражданнарнын һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, аларның саны авыл халкының гомуми саныннан 30 процентган артмаска тиеш. 2025 елда Аккүз авылындагы Михайловка авыл җирлеге территориясендә 1570(Бер мең биш йөз җитмеш) сум күләмендә бер тапкыр җыела торган түләү кертергә, һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :

1).Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: (грейдерлау, кардан чистарту, юл кырыйларын чаптыру).

2).Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

3.Әлеге карарны Аккүз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aktanysh.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Аккүз авыл җирлеге
Советы рәисе Г.И.Имамова